**КАРАР**
**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**23 ноябрь 2021 ел** **№ 01**

**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Армиясе сафларында ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 2700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Төркәш авылында өлешчә Чишмә урамы, өлешчә Үзәк урамы юлларына вак таш җәю (вак таш, ком, торбалар сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Төркәш авылында өлешчә Чишмә урамы юлына асфальт җәю (асфальт сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза уздыру);
- Яңа зиратны өлешчә киртәләү (материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Төркәш авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Төркәш авылы юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Урам яктырткычларын алыштыру һәм карап тоту (яктырткычлар сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (су саклау каланчасы идарә щитын ремонтлау, Төркәш авылында су тараткыч башня өчен насос алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу, су зонасы коймаларын ремонтлау)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 166 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 101 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 101 кеше тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең **Төркәш** авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «« Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Армиясе сафларында ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 2700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Төркәш авылында өлешчә Чишмә урамы, өлешчә Үзәк урамы юлларына вак таш җәю (вак таш, ком, торбалар сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Төркәш авылында өлешчә Чишмә урамы юлына асфальт җәю (асфальт сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза уздыру);
- Яңа зиратны өлешчә киртәләү (материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Төркәш авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Төркәш авылы юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Урам яктырткычларын алыштыруһәм карап тоту (яктырткычлар сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (су саклау каланчасы идарә щитын ремонтлау, Төркәш авылында су тараткыч башня өчен насос алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу, су зонасы коймаларын ремонтлау?

«РИЗА» «КАРШЫ» »

кабул ителгән дип таныргa.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Нырты авыл җирлеге башлыгы Т. А. Котдусов

НЫРТИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО района РТ
ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ районы НЫРТЫ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ОГРН 1061675011243
ИНН 1623008592